
Боек скульптор Степан Дмитриевич Эрьзянын тууына 150 ел тулуга багышланган зур күргәзмә башланырга азрак вакыт кала. Тантаналы ачылыш 31 мартта Санкт-Петербургтагы Рус музеенда узачак. Юбилей күргәзмәсе атаклы скульпторнын әсәрләрен Санкт-Петербургтан Мәскәүгә, Третьяков галереясенә күчәчәк. Ә без, Мордовиялеләр, олы скульпторнын олы ижатын яктырткан музеенда һәр кон була алабыз.     Мәскәүдә «Степан Эрьзя ижатында хатын-кыз образла-ры» күргәзмәсе С.Д.Эрьзя исемендәге халыкара сәнгать фонды һәм Внуково халыкара аэропортынын уртак проекты ярдәмендә момкин булды. Исегезгә тошерәбез, быел боек скульпторынын 150 еллыгы тантаналы рәвештә билгеләп үтелә һәм яна күргәзмә - анын ижатын яратучыларга искиткеч бүләк. Күргәзмәне март уртасына кадәр бушлай Внуково аэропортынын оченче катында карадылар. Фонд вәкилләре билгеләп үткәнчә, күргәзмә 16 стендтан торган. Бу хатын – кыз скульптураларынын 13 сурәте- Степан Дмитриевичнын танылган шедеврлары, шулай ук останын биографиясе һәм анын ижаты турында сойләү белән стендлар да булган.
Степан Эрьзянын 150 еллык юбилеен бәйрәм итү кысаларында Мәскәү, Питер һәм Саранск халкын тагын бик күп кызыклы күргәзмәләр, семинарлар һәм конференцияләр котә.
- 31 марттан 7 июньгә кадәр Петербургта Эрьзя юбилее хормәтенә топ күргәзмәләрнен берсе узачак, - дип сойләде С.Д.Эрьзя исемендәге музей директоры Людмила Нарбекова. - Безнен даими экспозициядә Степан Дмитриевичнын 100 дән аз гына артыграк әсәре бар. Анын 50 эше тоньяк башкалага китәчәк. Күчмә күргәзмәләр үткәрүдә зур тәжрибәбез бар: транспортлау вакытына саклау очен, барлык скульптуралар аеруча нык конструкцияле, климат-контрольле тартмаларга тореләчәк, аларда даими температура саклана.
Июль аенда Эрьзянын эшләрен Мәскәүгә - Дәүләт Третьяков галереясенә күчерәчәкләр. Саранс шәһәрендә шедеврлар октябрь ахырында гына кайтачак. Фондларыбыздан скульпторнын тагы 45 эше күтәреләчәк. Бу скульптураларнын күбесен Саранск халкы беренче тапкыр күрәчәк.

**Н.ХӘЛИЛ**